ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**21.12.2020**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 2520**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «2020-2025 елларга Зеленодольск муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 24 ноябрендәге 2241 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль Закон, 2007 елның 4 декабрендәге «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 329-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы халкының һәрьяклап үсеше, физик яктан камилләшү һәм сәламәтлеген ныгыту өчен шартлар тудыру максатыннан, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «2020-2025 елларга Зеленодольск муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 24 ноябрендәге 2241 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә, «Муниципаль программа нәтиҗәләрен бәяләүнең һәм программа чаралары буенча финанслауның максатлары, бурычлары, индикаторлары» дигән бүлекнең «Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанслау» 4 пунктын яңа редакциядә раслап (Кушымта),
2. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигына әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының спорт бүлеге начальнигына йөкләргә.

Җитәкче И. Р. Ганиев

Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районының
Башкарма комитетының
карарга кушымта
21.12.2020 №2520

| 4. Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына финанслау | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмаларын җиһазлау өчен спорт җиһазлары, инвентарь һәм экипировка сатып алу | РТБ | ел дәвамында | 1 139 400,00 | 1 139 400,00 | 0 | 0 | 0 | 0 | ТР ЗМР БК СБ | Спорт инвентаре, җиһазлар һәм экипировканы яхшырту һәм яңарту |
| Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә-яшь белгечләргә түләү | РТБ | ел дәвамында | 95 500,00 | 95 500,00 | 0 | 0 | 0 | 0 | ТР ЗМР БК СБ | Матди ярдәм |
| Югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен, шулай ук ярышларда алган нәтиҗәләре өчен спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга түләүләр | РТБ | ел дәвамында | 2 580 000,00 | 2 580 000,00 | 0 | 0 | 0 | 0 | ТР ЗМР БК СБ | Матди ярдәм |
| Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмалары | | ел дәвамында | 151 300,00 | 151 300,00 | | | | | ТР ЗМР «Ледокол» СМ» МАУ | Спорт чаралары санын, спорт чараларында катнашучы халык саныч арттыру |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| командаларының хоккей буенча Татарстан Республикасы чемпионатында, хоккей буенча Россия Федерациясе чемпионатында катнашуларын һәм спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашыру | РТБ | | | | 0 | 0 | 0 | 0 | | |
| Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә үсеш өчен шартлар тәэмин итүгә бәйле чараларны гамәлгә ашыру, физик культураны, массакүләм спортны үстерү, модульле чаңгы базасын сператив идарәгә тапшыруга бәйле рәвештә, муниципаль биремне үтәүне финанс белән тәэмин итү күләмен арттыру өчен, рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын оештыру һәм үткәрү | РТБ | ел дәвамында | 496 340,00 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | ТР ЗМР «Васильево штп 2 нче СМ»МБУ | Яна спорт объектын финанслашу |
| | МБ | ел дәвамында | 5 013,54 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | ТР ЗМР «Васильево штп 2 нче СМ»МБУ | Яна спорт объектын финанслашу |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә физик культура, массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итүгә, рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыруга, муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр тарафыннан спорт әзерлеге буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль йөкләмәне финанс ягыннан тәэмин итү максатларында әлеге учреждениеләрдә шөгыльләнүче спортчыларны ташу буенча хезмәтләр аутсорсингка бәйле чыгымнар өлешендә гамәлгә ашыру. | РТБ | ел дәвамында | 960 000,00 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | ТР ЗМР БК СБ | Аутсорсинг: спорт учреждениеләрендә шөгыльләнүче спортчыларны ташу хезмәте |
| | | | | | | | | | | |
| | МБ | октябрь, ноябрь, декабрь | 40 500,00*** | | | | | | | |

*** - әлеге сумма белешмә рәвештә күрсәтелгән, чөнки 3 бүлектә исәпкә алынган. «Спорт учреждениеләре белән эшләү буенча чаралар», 5п. Татарстан Республикасының «Сәламәтлек» XVII авыл Спартакиадасында катнашу.